# *I. Музей эшчәнлегенә гомуми характеристика*

Безнең “Авыл тарихы” музее 1998 елда оешты. Ул “Мәктәп музее“ статусын йөртә. Бередәге экспонатлар Алтын Урда чорыннан башлап бүгенге көнгәчә тарихны үз эченә ала. Укучыларның тарихи үткәнебез белән кызыксынуын үстерүдә, үз Ватанын, туган ягының каһарман шәхесләрен, тынычлык хакына корбан булган якташларын белү һәм кадер-хөрмәт белән искә алу бурычын күңелләренә сеңдерүдә, балаларда милли горурлык хисе тәрбияләүдә музейның роле бик зур (Кушымта №1).

Музей экспозицияләре тематик рәвештә урнаштырылган.Беренче экспозиция “Тау ягым син, туган ягым, иң җылы бер почмагым”, “Узганнарга кайтып гыйбрәт ал” дип исемләнгән. Биредә Мөрәле авылының барлыкка килү тарихы риваятьләре, төрле чорларга караган язма һәм матди экспонатлар урын алган.




Икенче экспозиция “Данның төбе – хөрмәт, хөрмәт төбе- хезмәт” һәм “Горурланам авылым синең белән, үстергәнсең данлы шәхесләр” дип атала. Биредә колхоз производствосында эшләп дан-шөхрәт казанган, читкә китеп югары үрләр яулаган авылдашларыбыз турында информация тупланган. Алар арсында гади сыер савучы һәм механизатор да, фән эшлекләләре һәм Герой -ана да бар.




"Мәктәбем- яшьлек чорым" экспозициясендә төрле чорларда мәктәп статусы һәм анда эшләүче укытучылар турында мәгълүматлар урын алган.





“Эш күрсәткән ирне ил онытмас” исемле экспозиция колхозыбызны төрле чорларда җитәкләгән шәхесләр турында сөйли. Стендтагы шигъри юллар аларның фидәкарьлегенә гимн булып яңгырый:

Күпләр туып-үсте монда,
Монда чөйде җирәбәсен.
Кемдер кала , кемдер китә
Аңламыйча җир бәясен.

Тик шундыйлар ала монда,
Елар чакта түзсә, көлсә,
Сукранмыйча күн итеген
Көн дә юып кия белсә.



Бөек Ватан сугышы тарихына багышланган экспозицияләрнең беренчесе “Мин ант иттем җанны кызганмаска, саклар өчен газиз илемне” дип атала.




Биредә Мөрәле авылыннан сугышка китүчеләр исемлеге урын алган. Ә икенче экспозиция “Җиңүләрне яулап алган көннәр онтылмаслар гомер-гомергә” дип атала. Биредә сугыштан исән-сау әйләнеп кайткан авылдашларыбызның фотосурәтләре урнаштырылган. Ни кызганыч, хәзер аларның берсе дә исән-сау түгел инде. Сугын ветераннары белән беррәттән Әфган сугышы ветераннарының да фотосурәтләре музейда урын алган. “Солдатта булган диләр” исемле стендта Россия кораллы көчләре сафында хезмәт иткән егетләребезнең фотосурәтләре урнаштырылган.


2015
70
ел


САКЛАР ӨЧЕН
ГАЗИЗ
1941
1945





Авылдашларыбызның сугыш батырлыклары өчен бүләкләр.



Музейга килеп кергәч, татар мөхитенә кереп киткәндәй буласың. Биредә милли орнамент, татарс ирләре һәм хатын-кызларының кием, өй җиһазлары үрнәкләре, хуҗалык кирәк-яракларын яктырткан экспонатлар бизәлеш тапкан. Игенче хезмәтенә дан җырлаган экспозиция – музейның аерым бер бизәге.

“Авыл тарихын өйрәнү” студиясе әгъзалары белән шәҗәрәләр төзү өстендә дә эш алып барабыз. Ул “Җиде буыныңны бел!” дигән тематиканы били.





Төзеде Вафина Алия

Музейда Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе дәүләт символлары да саклана.















Музеебызда укучылар өчен экскурсияләр, хезмәт алдынгылары, тыл һәм хезмәт ветераннары белән очрашулар, батырлык сәгатьләре үткәрелә. Өлкәннәр көне уңаеннан үткәрелә торган чәй эчү мәҗлесләре алдыннан авылыбыз аксакаллары музей эчендә Аллаһыбызның рәхмәте өчен дога колалар.

“Авыл тарихын өйрәнү” студиясе әгъзалары ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты һәм шушы иститут белән берлектә Казан дәүләт федераль университеты үткәрә торган республика, Каюм Насыйри исемендәге фәнни-тикшеренү эшләре регионара конкурсларында катнашып призлы урыннар яулыйлар (Кушымта № ).

Музей базасында район тарих укытучылары методик берләшмәсенең семинарлары үтә. Яшь мөгаллимнәргә туган төбәк тарихын өйрәнү буенча киңәшләр бирелә.




“ФГОС ка күчү шартларында гражданлык-патриотик тәрбияне оештыру” темасына багышланган тарих укытучыларының  район семинары.



“Белем бирүне модернизацияләү шартларында предметны укытуның инновацион үсеше” темасына үткәрелгән зона семинарында катнашучыларга музейда экскурсия.

Мәктәбебезнең “Авыл тарихы” музее Галия Кайбицкая исемендәге район музее белән хезмәттәшлек итә, укучылар бу музей тарафыннан үткәрелә торган төрле чараларда катнашалар, музейны экспонатлар белән баетуда булышлык күрсәтәләр.

Мәгърифәт һәм сәнгать

## Үткәннәрне бүгенге белән тоташтыручы күпер




**Музей директоры Әлфия Закирова Мөрәле урта мәктәбе укучысы Айсылу Шәфигуллинадан котлау кабул итә**

**30 октябрьдә Олы Кайбычтагы Галия Кайбицкая музее ачылуга 10 ел тулуны билгеләп үттек.**

Гөлия ГЫЙЛӘҖЕВА.

Бәйрәмгә кунак буларак чакырылган муниципаль район башлыгы урынбасары Рәмис Хәялиев үз чыгышында район җирлегендә күренекле якташыбыз истәлегенә моннан 10 ел элек музей ачылуы искиткеч олы вакыйгага әйләнгән иде, диде. Район җитәкчелеге һәм республиканың дәүләт Милли музее ярдәме белән төзелә ул. Бүгенге көндә дә ул Россия музейлары берлеге әгъзасы булып тора.

Бәйрәм тантанасына Галия Кайбицкая иҗатын яратаучылар, урта мәктәп укучылары, үзешчән шагыйрәләр дә чакырылган иде. Музейның беренче директоры, район башкарма комитетының архив бүлеге начальнигы Мәрьям Шәфигуллина музей төзелеше, беренче экспонатларны туплау юнәлешендә нинди эш алып барылуы хакында сөйләде, истәлекләре белән дә уртаклашты. Мәүлиха Айзатуллина, Әлфия Гыймадиева Татарстанның беренче халык артисты, “Почет” билгесе һәм Хезмәт Кызыл байрагы орденнары кавалеры, күп мәртәбәләр Казан шәһәре Советы депутаты булган опера җырчысы Галия Кайбицкаяга, музейга багышлап язылган шигырьләрен укыдылар. Укучылар да бәйрәм чыгышлары әзерләп килгән иде. Бөек Ватан сугыш ветераны, ветеран- укытучы Сәетгәрәй Закировның килене Лилия аның гомере буе туплаган архивын музейга бүләк итте.

Музей директоры Әлфия Закирова әйтүенчә, яшь буында туган якка мәхәббәт тәрбияләүдә музейның роле зур. 10 ел дәвамында биредә республика күләмендәге чаралар, истәлекле көннәргә багышлап музей-дәресләр, әдәби- музыкаль кичәләр уздырыла. Шул ук вакытта кул эшләре күргәзмәләре дә еш оештырыла. Музейның “Теләкләр һәм тәкъдимнәр” китабында күренекле шәхесләрнең, язучы-галимнәрнең язма, фикерләре тупланып бара.


10 ел тарих өчен мизгел генә булып тоелса да, буш җирлектә сафка бастырылган музей бу еллар эчендә меңләгән кешене кабул итеп, аларга мәшһүр җырчы турында бай мәгълүмат бирергә өлгерде.

## Музейларда – халык хәтере

*Музейларда йөрдем–заллар буйлап,*
*Тарих эзе – безнең үткән юл.*
*Бабайлардан калган мирас-ядкарь*
*Безнең көнгә килеп җиткән ул.*
*Мәдәният, телне, динне саклау –*
*Һәрбер чорда булмаган җиңел.*
*Каршылыклар тулы көрәш юлы...*
*Бүген дә ансат кына түгел.*
*Ыгы-зыгы, дөнья мәшәкате,*
*Мең төрле эш баштан, муеннан*
*Бу тормышның кадерен белер өчен*
*Борылып кара үткән юлыңа.*
*Безнең бурыч – кыйммәт җәүһәрләрне*
*Киләчәккә илтеп җиткерү.*
*Үткәнне белмәсәң, киләчәк юк,*
*Музейларда – халык хәтере.*

**Әлфия Гыймадиева,**
**Борындык.**

Мәктәп укучылары Музей советы белән берлектә Республикабызның төрле төбәкләрендәге музейларга экскурсияләр оештыралар, алган тәэсирләре турында түбән класс укучылары белән уртаклашалар.



Шәһре Болгарга сәяхәт




Алабуга шәһәрендә Надежда Дурова музеенда




Кавалерист кыз Надежда Дурованың сугыш аты өчен кирәк булган экспонатлар.

*Музейларда – халык хатирәсе. Шуларны киләчәк буыннарга җиткерү – һәр тарих укытучысының приоритетлы эшчәнлеге булырга тиеш.*